СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с. Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)5-23-93, факс (84 3665-23-93). E-mail: Kach.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“03” июль 2025 ел** **№ 135**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең генераль планын әзерләү кирәк булмау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге территориясендә гамәлдәге җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмау, расланган комплекслы социаль-икътисади үсеш программасы булмау һәм Татарстан Республикасы һәм Арча муниципаль районы территориаль планлаштыру схемалары белән федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыру каралмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2026 елның «31» декабренә кадәр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең генераль планын эшләү кирәк булмавын танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның «01» гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Р.Р.